КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 апрель г.Казань № 304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосындагы яшьләр сәясәтенең дәүләт оешмалары һәм аерым типик булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 21 июнь, 505 нче, 2020 ел, 31 гыйнвар, 54 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 9 февраль, 102 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосындагы яшьләр сәясәтенең дәүләт оешмалары һәм аерым типик булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Яшьләр театрлары өчен:

«труппа мөдире», «вокал буенча репетитор», «балет артисты», «драма артисты», «симфоник, камера, эстрада-симфоник, рухи оркестрлар, халык инструментлары оркестры артисты» вазыйфаларында эшләүче хезмәткәрләрнең төп оклады:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белеме, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белеме, тулы булмаган югары белеме булганнарга 14 487 сум тәшкил итә;

аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен биреп раслана торган югары һөнәри белеме булганнарга 16 720 сум тәшкил итә.

«баш дирижер», «баш режиссер», «әдәби-драматургия өлеше җитәкчесе», «әдәби-сәхнә өлеше мөдире», «музыкаль өлеш мөдире» вазыйфасын биләгән хезмәткәрләрнең төп окладыು:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белеме, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белеме, тулы булмаган югары белеме булганнарга 21 171 сум тәшкил итә;

аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен биреп раслана торган югары һөнәри белеме булганнарга 24 421 сум тәшкил итә.»;

V бүлектә 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.2 - 1.4 пунктчалар өстәргә:

«1.2. «Яшьләр белән эшләү буенча белгеч» һәм «яшьләр белән социаль эш буенча белгеч» вазыйфаларын биләгән хезмәткәрләргә кызыксындыру характерындагы түләүләр яшьләр сәясәте оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең икенче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары өчен түләү белән тиңләштерелә.

1.3. “Трупа мөдире”, “вокал буенча репетитор”, “балет буенча репетитор”, “артист-вокалист (солист)”, “балет артисты”, “оркестр артисты”, “хор артисты”, “драма артисты”, “симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр, халык уен кораллары оркестры артисты”, “җыр һәм бию ансамбле артисты”, «эстрада оркестры (ансамбль) артисты», «җыр һәм бию ансамбле балеты, бию коллективы артисты», «җыр һәм бию ансамбле хоры, хор коллективы артисты», «артистлар - концертлар башкаручылар (барлык жанрлар), ярдәмче составтагы концертлар башкаручылардан тыш» вазыйфаларын биләгән хезмәткәрләргә кызыксындыру характерындагы түләүләр яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең алдынгы звеносы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары өчен түләүләр белән тиңләштерелә.

1.4. «Баш дирижер», «баш режиссер», «әдәби-драматургия бүлеге җитәкчесе», «музыкаль өлеш мөдире» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләргә кызыксындыру характерындагы түләүләр яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы хезмәткәрләре вазыйфалары өчен түләүләргә тиң булырлык итеп исәпләнә.»;

15 нче таблицага:

түбәндәге эчтәлекле 3.10 - 3.14 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «3.10. | Труппа мөдире | 45 |
| 3.11. | Вокаль буенча репетир | 45 |
| 3.12. | Балет артисты | 45 |

| | | |
|---|---|---|
| 3.13. | Драма артисты | 45 |
| 3.14. | Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр, халык уен кораллары оркестры артисты | 45»; |

түбәндәге эчтәлекле 4.7 - 4.11 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «4.7. | Баш дирижер | 55 |
| 4.8. | Баш режиссер | 55 |
| 4.9. | Әдәби-драматургия өлеше җитәкчесе | 55 |
| 4.10. | Сәнгать-сәхнә өлеше мөдире | 55 |
| 4.11. | Музыкаль өлеш мөдире | 55». |

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин